КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 1 июль г.Казань № 481

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясындагы 2 өлешенең $10^{12}$ пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү проектларын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 24 сентябрь, 913 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 4 апрель, 311 нче; 2023 ел, 9 октябрь, 1268 нче; 2023 ел, 29 декабрь, 1742 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителә торган территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру максатларында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы белән төзелә торган килешүне төзү һәм Татарстан Республикасы билгеләгән һәм территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган юридик зат тарафыннан гамәлгә ашырылу кагыйдәләре.»;

әлеге карар белән расланган Җирле үзидарә органнарының яки шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимият органының җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының

хокук ияләре белән, территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү хокукына торглар үткәрмичә, мондый шартнамәне төзү тәртибендә:

2 пунктта «территорияне комплекслы үстерү чикләрендә» сүзләреннән соң «, линия объектларының хокук ияләреннән тыш,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Шартнамәдә территорияне планлаштыру документлары турында белешмәләр булырга мөмкин, аның нигезендә территорияне комплекслы үстерү гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14. Әгәр хокук ияләренә шартнамә проекты җибәрелгән көннән 60 календарь көн үткәннән соң, хокук иясе тарафыннан кул куелган шартнамә вәкаләтле органга тапшырылмаган булса, вәкаләтле орган мондый шартнамәне төзүдән баш тарту турында карар кабул итәргә хокуклы.»;

әлеге карар белән расланган Территорияне комплекслы үстерү турында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы яки шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы тарафыннан кабул ителгән булса, территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру тәртибендә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән очракларда, сатулар территорияләрне комплекслы үстерү турында ике һәм аннан күбрәк шартнамә төзү хокукына үткәрелергә мөмкин.»;

әлеге карарга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителә торган территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру максатларында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы белән төзелә торган килешүне төзү һәм Татарстан Республикасы билгеләгән һәм территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган юридик зат тарафыннан гамәлгә ашырылу кагыйдәләрен (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2007 ел, 18 май, 196 нчы; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы; 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы; 2010 ел, 14 октябрь, 808 нче; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы; 2013 ел, 7 март, 152 нче; 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы; 2013 ел, 10 август, 558 нче; 2014 ел, 21 апрель, 261 нче; 2015 ел, 1 июнь, 397 нче; 2016 ел, 10 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 13 декабрь, 925 нче; 2017 ел, 6 март, 127 нче; 2017 ел, 26 май, 309 нчы; 2017 ел, 14 ноябрь, 867 нче; 2018 ел, 4 июль, 545 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1107 нче; 2018 ел, 14 декабрь, 1135 нче; 2019 ел, 16 апрель, 301 нче; 2019 ел, 21 май, 416 нчы; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 13 июль, 576 нчы; 2019 ел, 12 октябрь, 907 нче; 2020 ел, 10 февраль, 83 нче; 2020 ел, 18 май,

400 нче; 2020 ел, 28 май, 436 нчы; 2020 ел, 13 июль, 577 нче; 2020 ел, 10 октябрь, 917 нче; 2020 ел, 27 октябрь, 962 нче; 2020 ел, 2 декабрь, 1087 нче; 2021 ел, 31 август, 790 нчы; 2022 ел, 1 апрель, 306 нчы; 2022 ел, 16 июнь, 567 нче; 2022 ел, 22 декабрь, 1395 нче; 2023 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2023 ел, 6 март, 221 нче; 2023 ел, 2 июнь, 676 нчы; 2023 ел, 10 октябрь, 1292 нче; 2023 ел, 29 декабрь, 1721 нче; 2024 ел, 16 февраль, 86 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.3 пункттагы 3.3.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы билгеләгән һәм территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган юридик зат белән килешү төзү;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 сентябрь, 913 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 1 июль, 481 нче карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителә торган территорияне комплексլы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру максатларында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы белән төзелә торган килешүне төзү һәм Татарстан Республикасы билгеләгән һәм территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган юридик зат тарафыннан гамәлгә ашырылу
кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 71 статьясындагы 7 өлеше, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^{1}$ статьясындагы 2 өлешенең $10^{12}$ пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителә торган территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру максатларында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы белән төзелә торган килешү (алга таба – килешү) эчтәлеген, аны төзү очрагын һәм Татарстан Республикасы билгеләгән һәм территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган юридик зат (алга таба – юридик зат) тарафыннан гамәлгә ашырылу тәртибен билгели.

2. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимият органы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Карар, әгәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә кабул ителә торган территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру юридик зат тарафыннан тәэмин ителгән булса, кабул ителә.

4. Килешү төзү максатларында юридик зат Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан территорияне

комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән көннән алып 20 эш көне эчендә килешү проектын әзерләүне тәэмин итә һәм аны Министрлыкка, җирле үзидарәнең вәкаләтле органына җибәрә.

5. Килешүгә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 68 статьясындагы 4 өлеше нигезендә территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамәгә кертелергә тиешле белешмәләр һәм шартлар кертелә. Торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы карарын гамәлгә ашыру максатларында төзелә торган килешүгә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 68 статьясындагы 6 өлеше нигезендә территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамәгә кертелергә тиешле белешмәләр һәм шартлар кертелә.

6. Килешүдә әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктында каралган белешмәләр һәм шартлар белән беррәттән, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 68 статьясындагы 5 һәм 7 өлешләре нигезендә территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамәгә кертелергә тиешле белешмәләр һәм шартлар, шул исәптән башка белешмәләр һәм шартлар (кирәк булганда) кертелергә мөмкин.

7. Әлеге Кагыйдәләрнең 6 пунктында каралган башка белешмәләр һәм шартлар буларак килешүгә шул исәптән аңа үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шулай ук юридик зат тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 71 статьясындагы 3 өлешендә каралган территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамәгә комплекслы үстерелергә тиешле территорияне әзерләү буенча (дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләре һәм (яисә) аларга урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары өчен түләүләрне кертеп), шулай ук расланган территорияне планлаштыру документациясе нигезендә коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектларын, башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау буенча чыгымнарны каплау өчен акча түләүне яисә бирүне кертү зарарлыгы кертелергә мөмкин.

8. Килешү проекты кабул ителгән көннән алып 20 эш көне эчендә Министрлык, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы килешү проектының территорияне комплекслы үстерү турындагы карар предметына, шулай ук әлеге Кагыйдәләрнең 5 – 7 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә.

9. Килешү проекты территорияне комплекслы үстерү турындагы карарга һәм (яисә) әлеге Кагыйдәләрнең 5 – 7 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгәндә һәм (яисә) килешү проекты эчтәлегенә карата искәрмәләр булганда, Министрлык, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы килешү проектын юридик затка эшләп бетерү өчен кире кайтара.

10. Әлеге Кагыйдәләрнең 9 пунктында каралган очракта, юридик зат килешү проекты буенча кисәтүләр кергән көннән алып 20 эш көне эчендә аны эшләп бетерә һәм эшләнеп беткән килешү проектын тиешенчә Министрлыкка, җирле үзидарәнең вәкаләтле органына җибәрә. Министрлык, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы белән килештереп, кисәтүләрне бетерү срогы 40 эш көненә кадәр озайтылырга мөмкин.

11. Кисәтүләр булмаганда Килешү проекты әлеге Кагыйдәләрнең 8 пунктында каралган срок тәмамланган көннән алып 10 эш көне эчендә юридик зат һәм Министрлык, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы белән төзелергә тиеш.

12. Килешүне гамәлгә ашыру максатларында юридик зат килешүдә билгеләнгән срокларда:

комплекслы үсеш территориясен планлаштыру документациясен әзерли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Министрлыкка, җирле администрация башлыгына раслауга кертә (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 66 статьясындагы 10 өлешендә каралган очрактан тыш);

җирлекнең генераль планына, шәһәр округының генераль планына, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү инициативасы белән чыга (кирәк булганда);

карарга кертелгән капиталь төзелеш объектларын сүтү яисә реконструкцияләү чиратын күрсәтеп, территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру этапларын билгели (кирәк булганда);

территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыруның билгеле бер этапларына һәм максималь срокларына туры китереп, комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территориядә капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыра.